# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Ләке торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 18 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә 14.00 сәгатьтә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. «2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пункты территориясендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә җыярга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) Ләке торак пунктында зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) Ләке торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3)Ләке торак пунктындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру);
4)Ләке торак пунктында махсуслаштырылган МТЗ-82 техникасы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу;
5)МТЗ тракторы өчен чапкыч сатып алу 82.1;
6)Ләке торак пунктында җәйге вакытта (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эш һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) территорияне һәм юл буе полосаларын чаптыру;
7)Ләке авыл җирлегендә "Питрау" бәйрәменә призлар һәм бүләкләр сатып алу;
8)Ләке торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 269 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 141 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

позиция өчен гражданнар җыенында 141 катнашучы тавыш бирде; каршы позиция өчен 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә халык җыены булып узды.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны танырга: «2023 елда Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешенең 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Ләке торак пунктында зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) Ләке торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3)Ләке торак пунктындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру);
4)Ләке торак пунктында махсуслаштырылган МТЗ-82 техникасы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу;
5)МТЗ тракторы өчен чапкыч сатып алу 82.1;
6)Ләке торак пунктында җәйге вакытта (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эш һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) территорияне һәм юл буе полосаларын чаптыру;
7)Ләке авыл җирлегендә “Питрау” бәйрәменә  призлар һәм бүләкләр сатып алу;
8)Ләке торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _______ Шәрипова Л. И.